**Югары Чура авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**2022 елның 10 ноябре** **№ 28**

Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында «Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 01 декабрендәге 1 номерлы Югары Чура авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставының 20 ст. нигезендә Югары Чура авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 25 ноябренә 15 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 01 декабрендәге 1 номерлы Югары Чурамавылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Чура авылы, Мэктэп ур., 34 адресы буенча мәдәният йортында үткәрергә

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 01 декабрендәге 1 номерлы Югары Чура авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктта:

унберенче абзацны киләсе редакциядә бәян итергә:

«-2021 елгы акчаларны махсус техника яллау һәм Югары Чура авылында агач кисү пункты буенча зиратны карап тотуга һәм төзекләндерүгә файдаланырга (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү );

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Югары Чура авыл җирлеге башлыгы: Андреев В.Н.